# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге
Текмәле авылында гражданнар
җыены нәтиҗәләре турында

**18.11.2023 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45- ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 18 ноябрендә узган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Текмәле авыл җирлегендә гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

«Сез 2024 елда Үчәлле авыл җирлеге Текмәле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, күпбалалы гаиләләрдән, һәм гаилә әгъзасы махсус хәрби операциягә мобилизацияләнгән гаиләләрдән тыш, 500 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан, түләүне киметеп, аны 250 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Урам яктыртуны тоту һәм хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар, урам яктыртуны ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләр сатып алу һәм алыштыру);
- Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тоту (юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре)

ӘЙЕ КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 18 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, гражданнар җыенда катнашып тавыш биргән гражданнар саны - 10 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«ӘЙЕ» позициясе өчен 10,
«КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Текмәле авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә (дөрес) дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: «Сез 2024 елда Үчәлле авыл җирлеге Текмәле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр

балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, күпбалалы гаиләләрдән, һәм гаилә әгъзасы махсус хәрби операциягә мобилизацияләнгән гаиләләрдән тыш, 500 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан, түләүне киметеп, аны 250 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Урам яктыртуны тоту һәм хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар, урам яктыртуны ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләр сатып алу һәм алыштыру);

- Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тоту (юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре).

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Үчәлле авыл җирлеге мәгълүмати стендында (Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 нче йорт; Ишкәй авылы, Текмәле урамы, 15 йорт), Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Үчәлле авыл җирлеге Башлыгы Г.М.Төхвәтуллина